СОВЕТ
ВВЕДЕНСКО-СЛОБОДСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ВВЕДЕНСКИЙ БИСТӘСЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Ул. Центральная, д.55, с. Введенская Слобода, 422591

Үзәк ур., 55 нче йорт, Введенский бистәсе ав 422591

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

28.11.2024 с. Введенская Слобода №41-331

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлеге территориясендә туристик салым кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 33.1 бүлегенә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга таянып,Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлеге Советы карар итте:

1. 2025 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлеге территориясендә туристик салым кертергә.

2. Турист салымы ставкасын түбәндәгечә билгеләргә:

- 2025 елда салым базасының 1 проценты күләмендә,
- 2026 елда салым базасының 2 проценты күләмендә,
- 2027 елда салым базасының 3 проценты күләмендә,
- 2028 елда салым базасының 4 проценты күләмендә,
- 2029 елдан башлап салым базасының 5 проценты күләмендә.

3. Әлеге карар, рәсми басылып чыккан көненнән 1 айдан да иртәрәк булмаган вакытта, 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Введенский Бистәсе авыл җирлеге башлыгы Д.В. Морозов